ХУҖАЛЫ ҖИР

Милек турында законнардагы мөһим үзгәрешләр

> 2

МОҢ ПАТШАБИКӘСЕ

Казанда Әлфия Авзалованың 90 еллыгын билгеләп үттеләр

> 3

БАШКАЛАДА КУНАКТА

«ВТ» хәбәрчеләре Татарстан районнары уздырган бәйрәмнәрдә булып кайтты

> 3

КОМАНДИР КУШКАН

Мамадышның үз «Путин»ы бар

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 157 (29124) | Чәршәмбе | 25 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

АЛТЫН ТЕШ

РОССИЯДӘ СТОМАТОЛОГИЯ ХЕЗМӘТЛӘРЕ КЫЙММӘТЛӘНЕРГӘ МӨМКИН

Теш табибына баруны кичектереп йөргән кешеләргә бу эшне якын арада эшләп кую хәерле. Ник дигәндә, белгечләр ел азагына кадәр Россиядә стоматология хезмәтләренә хаклар шактый кыйммәтләнәчәк, дип фаразлый. Белгечләрнең бер ише моны сумның тотрыксызлыгы, читтән кертелгән материалларның кыйммәткә төшүе белән аңлата. Араларында моны сезонлы күренеш дип атаучылар да бар. Ничек кенә булмасын, алдан аяк киенүнең зыяны юк.

«Түбән Кама Нефтехим» матбугат үзәге

Россиянең Стоматология ассоциациясе президенты Владимир Садовский Яңа елга кадәр илдә стоматология хезмәтләре уртача 30 процентка кыйммәтләнергә мөмкин дип фаразлый. Барыннан да бигрәк анестезия, пломба, имплант кую хакы артырга мөмкин, дип саный ул.

– Стоматология хезмәтләренә бәяләр шактый вакыт дәвамында тотрыклы сакланып килә. Кайбер хезмәтләргә хаклар артса да, котырып бәя үсү күзәтелмәде. Әмма шушы вакыт эчендә аларның чыгымнары шактый артты, читтән кертелгән материал, җиһазлар кыйммәтләнде. Бу, үз чиратында, түләүле хезмәт күрсәтүче табибларның хезмәт хакына да тәэсир итте. Тешкә бәйле хезмәтләрнең кыйммәтләнүендә моның да өлеше юк түгел, – ди Садовский.

Белгеч сүзләренә караганда, бүген илнең стоматология тармагында читтән кертелә торган материал, җиһазларга кытлык юк. Әмма логистика чыгымнары арту сәбәпле, алар да кыйммәтләнгән.

Гомеренең ике дистә елын теш дәвалауга багышлаган тәҗрибәле табиб Лилия Сибгатуллина исә ел азагына таба теш дәвалатуның кыйммәткәрәк төшүен сезонлы күренеш дип атый.

– Сентябрьдә кеше инде ял итәсен ял итеп бетергән, ныгытып эшкә тотынган, укулар башланган чорга аяк басабыз. Кеше, кагыйдә буларак, моңарчы кичектереп килгән башка мәшәкатьләрен кайгырта башлый. Теш дәвалау да шулар рәтендә, – ди табиб. – Монда психологик як та мөһим роль уйный. Кеше гел яңа елдан соң нидер үзгәрер дип көтә. Шул исәптән бәяләр дә. Шуңа күрә ел азагына кадәр элеккеге бәядән тешләрен дәвалап калырга теләүчеләр дә шактый. Ихтыяҗ күп булгач, бу хезмәтләргә бәя дә азмы-күпме арта.

Башкаладагы шәхси стоматология клиникасы җитәкчесе Александр Симонов сүзләренә караганда, бер ел эчендә аларда кайбер төр хезмәтләр 2–2,5 тапкыр кыйммәтләнгән. Моны илдәге икътисадый тотрыксызлык белән бәйли ул.

– Сум тотрыкланган очракта да безгә эш өчен кирәк-ярак сатучылар бәяне төшермәячәк. Мондый шартларда теш дәвалауга бәйле хезмәтләргә бәяне арттырмый хәлең юк. Аларның хакы алга таба да артачак. Ник дигәндә, без бүген катгый базар шартларында эшләргә мәҗбүр, – ди белгеч.

Симонов сүзләренә караганда, әлегә алар моңа кадәр чит илдән кайтарылган материаллар белән эшли. Аерым алганда, пломба буларак – Япониядә җитештерелгән, имплант куйганда Көньяк Кореядә эшләнгән кирәк-яракларны файдаланалар икән. Соңгы арада аларны сатып алу бәясе арткан. Бу исә, үз чиратында, шулай ук тешкә бәйле хезмәтләргә бәянең артуына китергән.

Сүз уңаеннан, ил халкының өчтән бере (29%) теш табибында ел саен уртача 30 мең сум акчасын калдырып чыга икән. Росгосстрах уздырган соңгы тикшеренү нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Респондентларның яртысы диярлек (45%) – бу максатта елына, күп дигәндә, 10 мең сум, 8 проценты – 30–50 мең сум, 3 проценты – 50–100 мең сум, 2 проценты 100 мең сумнан артыграк акча тота икән. Теш дәвалауның ни икәнен белмәгән бәхетлеләр дә шактый. Шул ук сораштыруда катнашучыларның 13 проценты: «Теш табибына бер тапкыр да барганым юк», – дип җавап биргән.

– Шулай да ел азагына кадәр хаклар, белгечләр фаразлаганча, 30 процентка ук артыр дип уйламыйм. Шәхсән үзебездә алар, күп булса, 10–20 процентка артыр дип торабыз, – ди җитәкче. – Стоматология хезмәтләренә бәяләрне арттырыр алдыннан башта җентекле анализ уздырабыз. Әгәр теге яки бу хезмәт күрсәткән өчен куелган бәя аның үзбәясен дә капламый башласа, ул очракта хакын арттырырга туры килә. Шуңа күрә прайстагы барлык хезмәтләр берьюлы түгел, аларның кайбер төрләре генә кыйммәтләнәчәк. Табыш артыннан кусаң, клиентларны да югалтып бетерүең бар.

Бүген теш дәвалау күпмегә төшә?

Хезмәт төре	Бәясе (сумнарда)
вакытлыча пломба кую	200–2250
даими пломба кую	900–9000
теш алдыру	1650 сумнан башлана
акыл тешен алдыру	3500–7000 сум
тешләрне чистарту	2500–2700 сумнан башлана

Бурычны кичерәләр

Татарстанның һәм тагын 11 төбәкнең бюджет кредитын түләүне җиңеләйтмәкчеләр. Россия Хөкүмәтенең матбугат хезмәте хәбәренә караганда, кредит бурычы 2022 елда республикада инвестицион проектларны гамәлгә ашырудан федераль бюджетка юлланган салым күләмендә кимeтелә. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин бу җәһәттән боерыкка кул куйган.

Татарстаннан тыш, Башкортстан, Алтай, Краснодар, Пермь крайлары кебек төбәкләр өчен шундый мөмкинлек ачыла. Алар яңа инвестицион проектларны эшләтеп җибәрү өчен транспорт, энергетиканы, коммуналь инфраструктураны бик нык үстерүчеләр булып танылган.

Төбәкләрнең барлыгы 8,2 миллион сумнан артыграк бурычын кичерү күздә тотыла. Бурыч йөге өстенлекле дип танылган тармакларда гамәлгә ашырылучы инвестицион проектлар буенча җиңеләйтелә. Болар – авыл хуҗалыгы, туризм, эшкәртү сәнәгате, торак һәм юл хуҗалыгы тармаклары.

Кишәрлек алучылар арта

Татарстанда 2011 елдан бирле күпбалалы гаиләләргә барлыгы 46673 җир кишәрлеге бирелгән. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин әйтүенчә, бушлай җир кишәрлеге алуның төп шартларыннан берсе – республикада кимендә 5 ел яшәү. Шул ук вакытта республика җитәкчелеге махсус хәрби операциядә катнашучы өч һәм аннан күбрәк балалы хәрбиләргә карата бу шартны юкка чыгарган.

Махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен тагын бер яңалык булырга тора. Министр сүзләренә караганда, «Россия Герое» исеменә лаек булган яки яу кырында батырлык, фидакарьлек өчен орденнар белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләргә бер тапкыр бушлай җир кишәрлеге бирү күздә тотыла. Яңалык үз ихтыяры белән махсус хәрби операциягә китүчеләргә, шулай ук Росгвардиядә хезмәт итүчеләргә дә кагыла. Министрлык шундый закон проекты әзерләгән. Аны ел азагына кадәр кабул итәргә җыеналар.

Күрсәткеч зурая

Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны арта. COVID-19 таралуга каршы көрәш буенча федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, 16–22 октябрь көннәрендә 368 кеше чирләгән. Әлеге сан алдагы атнадагыга караганда 29,6 процентка зуррак.

9–15 октябрьдә республикада 284 кеше чир йоктырган булган. Алдагы атнадагы белән чагыштырганда 34,6 процентка күбрәк бу. 2–8 октябрьдә 211 кешедә коронавирус ачыкланган.

Татарстанда пандемия башланганнан бирле чир йоктыруның барлыгы 208123 очрагы теркәлгән. 205398 кеше савыккан, 2010 сырхау вафат булган.

Ялга әзерләнәләр

Көзге каникулда республика лагерьларында 18 мең бала ял итәчәк. Шуның 15меңе – мәктәп яны лагерьларында. Яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков әйтүенчә, әлегә Роспотребнадзор идарәсе, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары, Гадәттән тыш хәлләр, Сәламәтлек саклау министрлыклары вәкилләре белән балаларның имин ялы өчен кирәкле әзерлек эшләре алып барыла.

Сүз уңаеннан, җәй көне Татарстаннан 150 мең бала (еллык планның 91 проценты) лагерьларда сәламәтлеген ныгыткан. Министр сүзләренә караганда, 91 проценттан калган өлеше көзге һәм кышкы каникулларда ял итәчәк.

tatarstan.ru

Без бергә!

Өзелмәсен өмет

ЯНГЫННАН ЗЫЯН КҮРГӘН ЙОЛДЫЗ АВЫЛЫ БҮГЕН НИ ХӘЛДӘ?

Курган өлкәсендәге Эчкен-Йолдыз авылы яңа гына тәпи басарга маташкан бала хәлендә. Май ае китергән утлы хәсрәттән соң тормышларын җайга салып, яшәргә өйрәнгән мәле андагы халыкның.

Бердәмлек көче

Кыска хәтерне яңартып үтик: Курган өлкәсендәге Эчкен-Йолдыз татар авылында быелның май башында зур янгын чыккан иде. Ике сәгать дигәндә, авылның яртысыннан артыгын ялкын теле камап алды, йортларны, мал-туарларны көлгә әйләндерде, җиде кешенең гомерен вакытсыз өзде. Әлеге фаҗигадән соң татар авылын торгызырга, яшәтергә кирәк дип, төрле дәрәҗәдә ярдәм күрсәтелә башлады. Татарстан да читтә калмады, билгеле. «ВТ» хәбәрчесе дә җәен Курган өлкәсенә барып, авылның көл өстендә ничек яшәвен күреп кайтты. Ул чакта: «Көзгә өй туйларын гөрләтербез әле!» – дип вәгъдә иткәннәр иде авыл халкына. Вәгъдәләр үтәләме? Авыл хәзер ничек яши? Нинди ярдәм көтәләр? Безне әнә шулар кызыксындырды.

«ВТ» хәбәрчесе элемтәгә чыккан көнне Бөтендөнья татар конгрессы делегациясе кабат Курганга сәфәргә җыена иде. Йолдызга барып, өй туенда катнашу, утырыш уздыру, халык белән очрашу исәпләре. Хәер, янгын чыккан авылга беренче генә барулары түгел инде. Ай саен барып, кирәк-яракларны тапшырып, ярдәм кулы сузып кына торалар. Чираттагы сәфәргә кузгалыр алдыннан Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең Россия төбәкләрендәге татар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү буенча беренче урынбасары Марс Тукаевтан Йолдыздагы вазгыять, ярдәм чаралары турында сораштык.

– Май аендагы фаҗигане бөтен татар халкы шәхси фаҗигасе буларак кабул итте. Беренче минутлардан ук ярдәм кулы сузучылар булды. Әлеге авылга 100 млн сумнан артык ярдәм күрсәтелде. Бөтендөнья татар конгрессы аша узган ярдәм турында сүз, – диде Марс Тукаев. – Авылда төзелеш дәвам итә. Без шуңа куанабыз: авыл мәктәбен саклап кала алдык. Моның өчен тырыштык, ярдәм күрсәттек. Анда хәзер уку процессы бара. Авылда калып укучы 63 бала бар. 5 кенә бала башка урыннарга күченеп китте. Без калган балалар өчен бердәм мәктәп киемнәре тектердек, букчалар бирдек, уку кирәк-яраклары тапшырдык. 1–11 сыйныф балаларына велосипед бүләк иттек. Тавыш аппаратурасы начар иде, яңа гына 160 мең сумга аппаратура алып бирдек. Китаплар, компьютерлар бүләк ителде, авыл мәктәбе ашханәсенә суыткычлар, плитәләр алып бирдек. Мәктәбе булмаган авыл бетүгә таба бара. Азмы-күпме анда татарча белем бирү бар. Шуңа да мәктәпне аеруча саклыйсы килде.

Марс Тукаев әйтүенчә, кием-салым, азык-төлек, материаллар белән булышучылар күп булган. Аерым төбәкләр дә авылны торгызуга күп көч куя.

– Күрше төбәкләр, диния нәзарәтләре, эшмәкәрләр йортлар җиткерергә булыша. «Татнефть» компаниясе 18 йортны сафка бастыра, – дип искәртте конгресс вәкиле.

Ахыры 4 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Сергей ИВАНОВ, Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе:

Туризм – кеше хезмәт куя торган тармак. Роботлар мондагы хезмәтнең бик аз өлешен генә алыштыра ала. Туристның барыбер сорауларын нәкъ менә кешегә бирәсе килә. Ресторанда аңа кешеләр хезмәт күрсәтә, экскурсовод та, машина йөртүче дә, музей хезмәткәре дә, кунакханәдәге хезмәткәр дә – тере кешеләр. Шуңа да туризм өлкәсендәге төп проблема – персонал, ягъни кешеләр җитмәү.

(«Татар-информ»)

ТАТАРСТАНДА – ГАИЛӘ ИНСТИТУТЫ

Татарстанда 1000 өйләнешүчегә 588 аерылышучы туры килә. Агымдагы елның сигез ае буенча Росстат тәкъдим иткән нәтиҗәләр шул хакта сөйли. Узган елның шушы ук чорында бу сан 6га кимрәк булган.

2023 елның гыйнвар – август айларында **16264 пар** өйләнешкән. Узган ел бу сан **0,2 процентка** күбрәк булган.

2023 елның гыйнвар – август айларында **9567 гаилә** таркалган. Узган ел бу сан **0,8 процентка** кимрәк булган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ – АМЕРИКА: ЯКЫН КӨНЧЫГЫШ ТИРӘСЕНДӘ ТАРТЫШ

Дөнья вакыйгаларының Фәләстыйн күчәре тирәсендә әйләнә башлавына өченче атна китте. Израиль көн саен коры җир операциясе башларга вәгъдә итсә дә, әлегә янаудан узмый. Бердән, дөнья җәмәгатьчелегенең басымы көчле. Икенчедән, сиончылар үз көчләренә ышанмый. Израиль югары җитәкчелеге арасында тарткалаш башлануы турында да хәбәрләр ишетелә. Сиончылар глобаль мәгълүмат сугышын ота алмады. Үзләренең дә, Вашингтондагы иганәчеләренең дә кем икәнлеген генә фаш иттеләр. Хәзер көчле цензура кертеп, Көнбатышта күтәрелгән протест хәрәкәтен туктатырга азапланалар. Израильнең үз эчендә дә аумакайлык бара: урамнарга чыккан халык ХАМАСка: «Нетаньяхуны алыгыз да безнең балаларны кайтарыгыз», – дип мөрәҗәгать итте. Гыйбри газетасы «Гаарец» Нетаньяхуның, җаваплылыкны үз өстеннән төшерү өчен, армиягә каршы дәлилләр җыюын хәбәр итә. Израильнең яңалыклар сайты Walla да шуны раслый.

Октябрь башында Америка чыганаклары Кытай лидеры белән Байденның ноябрь аенда Сан-Францискода очрашачаклары хакында язган иде. Пекин белән уртак тел табу американнар өчен үтә мөһим. Вашингтоннан хәтта ике арада салкынлык бетеп, дуслык чоры башланачак дигән хәбәрләр дә килгәләде. Әмма сишәмбе иртәсендә Синың Байден янына Сан-Францискога баруы әлегә паузада дигән мәгълүмат күренде. Кытайның үз эчендә проблемалар кискенләшә. Башта мәгълүмат кырыннан тышкы эшләр министры юкка чыкты, аннан соң – оборона министры. Ябык җәмгыять булганга, алар белән ни булганын чит ил разведкалары да өзеп әйтә алмады. Кытайлар әлегә кадәр парламент сессиясе җыеп, яңа оборона министры билгеләмәделәр. Ул арада Премьер-министр Ли Цян белән проблемалар башлануы турында имеш-мимешләр таралды. Әле чагыштырмача яңа сайланган җитәкчелекнең эшкә ярамавы андагы икътисадның авыр хәлен раслый. Кытай игътибарны тышкы конфликтларга юнәлтергә тырыша. Пекинның Якын Көнчыгышка алты хәрби кораб озатуына Израиль кризисының тулы масштаблы сугышка әйләнү ихтималлыгы сәбәпче, дип хәбәр итә британ газетасы «The Sun». Төбәк чиннар өчен шулай ук мөһим, алар анда үз йогынтыларын үстерергә һәм сакларга тырыша. Хәзер аналитиклар фаразлый: Кытай лидеры Сан-Францискодагы АТЭС саммитына барып, Байден белән очрашмаса, ике ил арасындагы киеренкелек үсәчәк. Пекин игътибарны Тайваньнан Якын Көнчыгышка күчерергә тырыша дигән фикер дә бар.

Россиядә

ИКЪТИСАДТА ТОТРЫКЛЫЛЫК, ӘММА АКЧА БИРӘҮГӘ ДӘ ҖИТМИ

Россиянең финанс кырыннан сөенечле хәбәр килә: сум ныгый. Бу юллар язылганда, доллар бәясе 94 сумга кадәр төште. «Төште» дип шартлы рәвештә әйтәбез, чөнки кайчан гына әле ул 65–75 сум тора иде. Белгечләр, җомга көнне Үзәк банк төп ставканы күтәрсә, доллар бәясе 92гә калыр, диләр. Төп ставканы күтәргәч, икътисад нишләячәк – анысын әйтеп тормыйлар.

Икътисад күрсәткечләре бик кызык ул: «Норникель», мәсәлән, өченче кварталда никель җитештерүне алдагы квартал белән чагыштырганда 21 процентка арттырган. Сан шулкадәр зур: шунда ук фанфаралар кагасы килә. Әмма 2022 елның шул ук чоры белән чагыштырганда, җитештерү 9 процентка кимүен ишеткәч, борын салына. Бакыр белән дә шул ук хәл: аны җитештерү быелның өченче кварталында, алдагы квартал белән чагыштырсаң, 6 процентка артык. Вәләкин үткән елгы күрсәткечләр янына куйгач, 12 процентка ким. Доллар курсы шикелле инде.

Җитештерү күрсәткечләренең аска-өскә уйнап торуына түзәр идең, акча җитми. HeadHunter тикшерүләре шуны күрсәтә: Россия халкының 45 процентына төп эш урынындагы хезмәт хакы гына җитми. 2021 елда андыйлар 25 процент булган. Респондентларның тагын 36 проценты хезмәт хакына көчкә очын-очка ялгап баруын әйтә. Арифметик исәпләү башкарыйк: халыкның 81 проценты акча кытлыгыннан интегә.

Ярый, халык нәфесен тыя алмаганга зарланды, ди. Сәяси җитәкчелек бит илдә эшләрнең майлаган кебек баруын әйтә һәм безнең аңа ышанмаска хакыбыз юк. Эре нефть компанияләре, ягулык өлешендә салымнар зур булуы сәбәпле, ваклап сатканда, зыян күрүләреннән зарлана. Салымнар, чынлап та, зур. Берәүләр, бензин бәясендә салым өлеше 75 процент, ди. Икенчеләр 80нән арттыра, кайсына ышанырга белмәссең. Әмма нефтьчеләргә бюджеттан демпфер түләнә. Октябрьдән аны йөз процент иттеләр, ягъни югалтуларны хөкүмәт йөз процентка каплый.

Бюджеттан акчаны күп бирү дә яхшыга илтми. Белгечләр, Россиядә ипотека куыгы кабара, дип чаң суга. Куык кабара икән, бераздан шартлый.

Бары тик авыл хуҗалыгы тармагында гына эшләр яхшы, ди, имеш. Ул табышка эшли. Табышны ашлама җитештерүчеләр ала ләкин. Ә авыл үзе 13 процент табыш ала икән. Бу – салымнарны түләгәнче исәпләгән сан. Салым түләгәч, кесәдә күпме акча калуы мәгълүм түгел.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

tatarstan.ru

ТИҢНӘР ЮК

Уңышка китергән осталык. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә чирәмдәге хоккей буенча «Динамо – Ак Барс» ир-егетләр командасын кабул итте. Казан клубы Россия чемпионаты суперлигасында җиңү яулаган иде.

– Сезне искиткеч җиңүегез белән котлыйм. Команда рухы, югары осталык, җиңүгә омтылыш рекордлы күрсәткечкә – 21 нче тапкыр Россия чемпионы титулына китерде, – диде Рөстәм Миңнеханов, команданы котлап.

Рәис искәрткәнчә, команда икенче ел рәттән яхшы күрсәткечләр белән сөендерә. Алар быел да ил чемпионы, Россия Кубогы һәм Суперкубок иясе булып танылды.

– Бу – Россия һәм Татарстан спорты өчен уникаль казаныш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул клубка ярдәм иткән кешеләргә дә, команда әгъзаларының гаиләләренә дә рәхмәтен әйтте.

– Команданың рухын ныгытуга гаиләләрегез, дусларыгыз, җанатарларыгыз һәм барлык татарстанлылар да өлеш кертә. Команданың уңышлары – республикада чирәмдәге хоккей үсешенә өстәмә этәргеч һәм үсеп килүче буын өчен яхшы үрнәк, – диде Рәис.

Рәхмәт сүзләренә команда да җавапсыз калмады. «Динамо – Ак Барс» командасының баш тренеры Араик Маргарян исә: «Татарстанда эшләвем белән горурланам һәм моның белән бәхетлемен!» – диде.

ТАТУЛЫК ҖИРЕ ИТЕП САКЛЫЙСЫ

Гомуми бурыч – алга таба да Татарстанны тынычлык-татулык җире итеп калдыру. Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Алексеевск районына эшлекле сәфәре барышында шулай диде. Бирегә ул «СинЭргия» яшьләр үзәген ачуда катнашты, Халыклар ассамблеясы советының күчмә утырышын үткәрде.

– Алексеевск районы – республикабыз кебек үк, күпмилләтле, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, утырышны ачып. – Бирегә милләтара тынычлык-татулыкны саклау, мәдәниятләр һәм традицияләрне, туган телләрне үстерү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Безнең иң зур кыйммәтләребез бу.

Парламент башлыгы искәртеп үткәнчә, республика Рәисе Дәүләт Советына еллык Юлламасында ата-бабаларыбызның тарихи хәтерен, мәдәни мирасны киләчәк буыннарга тапшыру зарурилыгына аерым игътибар юнәлткән. Халыкара хәлләр бик катлаулы булган бер мәлдә тынычлык-татулыкны саклау аеруча мөһим.

Алексеевск районы хакимияте башлыгы Сергей Демидов районда милли сәясәтне гамәлгә ашыру турында сөйләде. Бирегә 59 авыл-бистәдә 22 милләт вәкиле – барлыгы 25 мең кеше яши. «Мәдәниятләр һәм диннәр мәсьәләсендә бернинди каршылыклар юк. Безнең бурыч – һәр халыкның мәдәниятен саклау гына түгел, бәлки әле киләчәк буыннарга да тапшыру», – диде ул.

Утырышта миграция сәясәте мәсьәләсенә аерым тукталып үтелде. Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе җитәкчесе урынбасары Наталья Рыжикова сүзләренә караганда, Татарстан чит илдән килүчеләр саны буенча Идел буе федераль округында алдынгы урыннарның берсен били. Бары тик коронавирус пандемиясе чорында гына мигрантларның шактый кимүе күзәтелгән.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, соңгы вакытларда миграция хәлләре бездә дә, федераль дәрәҗәдә дә билгеле бер борчу тудыра. «Бүген халыклар арасында тынычлык, җәмәгать тәртибен һәм иминлек булдыру буенча безгә өстәмә бурычлар йөкләнде», – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе басым ясап әйткәнчә, республика вузларында белем алучы чит илләр студентлары белән эшне көчәйтергә кирәк. «Кайбер очрашулар үткәрдек. Нәтиҗәләр сөендерерлек түгел, мәгариф оешмалары җитәкчелеген бөтенләй бизәмәгән очраклар да бар, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Бу мәсьәләләрдә битарафлыкка юл куелмаска тиеш. Башка илләрдән килгән студентларның сыйфатлы белем һәм тәрбия алуы, рус телен белүе кирәк».

Парламент башлыгы сүзләренә караганда, республикага эшкә килүчеләрне кабул итү, урнаштыру мәсьәләсе белән тиешенчә шөгыльләнү дә мөһим. «Алар безнең икътисадый яктан нык үскән республикабызга эш эзләргә килә икән, без моны кайгыртырга тиеш. Алга таба да бергәләшеп күпмилләтле Татарстанны нәтиҗәле үстерү, тынычлык-татулыкны саклау максатында эшләячәкбез», – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин журналистларга.

Утырышта кайбер оештыру мәсьәләләре дә каралды. Аерым алганда, Сарман районында Татарстан халыклары ассамблеясы вәкиллеген ачу турында карар кабул ителде. Моннан тыш ассамблеяга яңа оешма керде. Татарстан белән Кытай арасында мәдәни традицияләр һәм гореф-гадәтләрне үстерү буенча «Кытай берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзалары ассамблеяга керү теләген белдерде.

ҺӘР КАРЫШЫ ХУҖАЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ

Җир хакы

Шулай ук һәр корылма да. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Росреестр һәм Роскадастрның Татарстан Республикасы буенча идарәләре белгечләре әнә шундый тәртип булдыру өчен тырыша. Халыкка ярдәмгә юнәлтелгән бу көрәш, һичшиксез, законнарга нигезләнеп алып барыла. Хөкүмәт йортында журналистлар белән булган брифингта әнә шундый документларга соңгы араларда кертелгән үзгәрешләр турында сүз барды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Авыл кешеләре дә, шәһәрнекеләр дә тагын бер кат үз хуҗалыкларындагы биналарга, җир кишәрлекләренә күз салсыннар иде. Барысы да рәсмиләштерелгәнме икән? Документлар тәртиптәме? Һәр кәгазьнең тәртиптә булуы эшне күпкә җиңеләйтәчәк, – дип киңәш итте җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин.

– «Элек исәпкә алынган күчемсез милекнең хокуклы хуҗаларын ачыклау турында»гы Закон нигезендә ташландык объектларның хуҗаларын эзләү эше күптән бара инде, – диде Росреестрның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова һәм бу җәһәттән бигрәк тә кемнәргә игътибарлы булырга кирәклеген санап чыкты: – күчемсез милек объектларына 1998 елның 31 гыйнварына кадәр хокуклары булган хуҗаларга; күчемсез милеккә хокуклары булып та, 2019 елның 1 февраленә кадәр хокуклары теркәлмәгән варисларга; пай кертемен түләп бетерү сәбәпле, милеккә хокуклары барлыкка килгән кешеләргә; күчемсез милеккә хокуклары 1998 елның 31 гыйнварыннан соң, әмма әлеге территориядә хокукларны теркәү буенча юстиция учреждениесе оештырылганчы теркәлгән очракта.

Республикабызда ташландык милекнең хокуклы хуҗаларын ачыклау максатыннан төрле чаралар уздырыла. Инде эзләп-эзләп тә табылмаса, вәкаләтле орган бу объектны хуҗасыз дип исәпкә кую өчен гариза язарга мәҗбүр була.

Лилия Борһанова «Гараж амнистиясе» буенча кертелгән яңалыкларны да барлап үтте. Соңгы үзгәрешләргә нигезләнеп, гәрчә территорияне ызанлаштыру проекты расланган булса да, кадастр планында җир участогының схемасын төзергә мөмкинлек тудырылган. Хәтта арендатор җирне берничә кешегә биргән очракта да, «гараж амнистиясе» кешегә үзе кулланган участокны аерым рәсмиләштерергә рөхсәт итә.

Соңгы елларда халык бакча ширкәтләрендәге йортларында яшәүне дә хуп күрә. Шуңа күрә аларны теркәү турында да сүз булды. Әйтергә кирәк, бу яктан хәлләр шактый җиңеләйгән: бүген бакча участокларындагы йортларны теркәү буенча бернинди чикләүләр дә юк.

Кайсы корылмалар «ярдәмче» булып таныла һәм аларны төзү өчен рөхсәт кирәкме? Бу сорауга да җавапны Росреестр белгечләре бирде. Корылмалар төп бина янында бер үк җир участогында төзелсә, бернинди каршылык та булмаячак. Мондый төзелешләр гадәттә төп объектның проект документларында каралырга тиеш. Алар гадәттә техник яктан катлаулы булмый, куркынычсызлык кагыйдәләре үтәлә, мәйданы 1500 кв. метрдан артмый. Шулай ук өч каттан артык булмаска, биеклеге 20 метрдан артмаска тиеш.

Хәрби хәрәкәтләр яки гадәттән тыш хәлләр вакытында җимерелгән объектларны Күчемсез милекне теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан чыгару өчен, аның хуҗасы Росреестрга гариза һәм кадастр эшләре нәтиҗәләре буенча әзерләнгән тикшерү акты тапшырырга тиеш. Акт вәкаләтле органнар тарафыннан бушлай төзелә. Бу очракта кадастр эшләре таләп ителми.

Күчемсез милек белән эш иткән, ягъни саткан, сатып алган, үзгәртеп корган, мираска калдырырга теләгән кешеләр игътибар иткәндер. Бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрдә еш кына хаталар килеп чыга. Болар – җир үлчәү, йорт-җирне документлаштыру эшләрендә элек-электән килгән җитешсезлекләр. Хәзер исә дәүләт программасын тормышка ашыру кысасында әлеге хаталарны төзәтү эше бара. Росреестр һәм Роскадастр белгечләре документларны үзләре тикшерә. Быел гына да шундый 23 мең хата төзәтелгән.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

✓ Әлеге закон гамәлгә куелганнан бирле (29 июнь, 2021 ел) **65 мең** күчемсез объектның хуҗасы ачыкланган. Хуҗасыз объектлар саны 70 процентка кимеп, **689 мең**нән **207 мең**гә калган.

✓ 2016–2023 елларда бакча ширкәтләрендә **109866 йорт** теркәлгән. 2022 елда бу сан – **20534**, 2023 елда – **16138**.

ТАТАРНЫҢ ҖАНЫ

КАЗАНДА ӘЛФИЯ АВЗАЛОВАНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕЛӘР

«Бакыйлыкка күчкәч тә, татар халкына хезмәт итүен бер көн дә туктатмады». Татар халкының моңлы сандугачы Әлфия Авзалованы шулай дип искә алдылар. Легендар җырчының 90 еллыгына багышланган гала-концертта III Халыкара фестиваль-бәйгенең Гран-при иясе дә билгеле булды.

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрына җыелган тамашачыны Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев сәламләде.

– Әлфия апа гомер буе милләткә хезмәт итеп, аның бөек шәхесенә әйләнде. Халык белән бергә тәрбияләнеп, аңа рәхмәтле булып, үз гомерен шушы һөнәргә багышлады. Минем зур горурлыгым – Әлфия апа белән берничә тапкыр төбәкләргә барып, Сабан туйларында катнашканым бар. Әлфия Авзалова була дигәч, Сабан туе икенче мәгънә ала иде. Анда килгән һәрбер кеше аның янына барып, исәнләшеп, хәлен белде. Ул, халыкка әмет биреп, рух өстәп килгән китә торган иде, – дип искә алды Васил Шәйхразыев. – Әлфия Авзалова лаеклы тормыш юлы үткән. Бер караганда авыр, икенче яктан бәхетле. Чөнки милләткә хезмәт итү зур тырышлык та, сәләт тә, зур теләк тә таләп итә. Әлфия апа бакыйлыкка күчкәч тә, татар халкына хезмәт итүен бер көн дә туктатмады. Аның җырлавын сәхнәдәге җырчылар да, гаилә бәйрәмнәрендә дә җырлыйлар. Ул үз эшен дәвам иттерә. Алдагы көннәрдә дә шулай булсын иде. Үз вакытында бөек шәхесебез Муса Җәлил «Җырларым» шигырендә: «Сез үлсәгез – мин дә онытылырмын, яшәсәгез – мин дә яшәрмен», – дигән. Татар яшәгәндә, Әлфия апаның исеме һәрвакытта иң алдынгы, иң лаеклы урыннарда булыр.

Милли шура рәисе үзенең күркәм гадәте буенча тамашачыны да җырлатты. «Бер куплет җырласак та, ул Әлфия апага дога булып барып ирешер», – диде ул. Зал тулы халык Әлфия Авзалованың мәңге үлмәс җырларын көйләде.

Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты, опера җырчысы Аида Гарифуллина үзенең видеосәламләвендә Әлфия Авзалова репертуарыннан бер әсәр башкарды.

– Әлфия Авзалова башкарган һәр җыр чын энҗегә әверелде. Аны юкка гына җыр патшабикәсе дип атамаганнар. Аның дөньяда барыннан да бигрәк җыры, тынлаучылары һәм тормышы яратканы сизелә иде. Әлфия Авзалова – татар халкының җаны ул. Ул башкарган җырлар әле бик озак еллар яңгыраячак, – диде җырчы.

Концерт мәшһүр җырчының тормышын тасвирлаган спектакль, күренекле җырчылар һәм Әлфия Авзалова исемендәге бәйге лауреатлары чыгышлары белән үрелеп барды. Халыкара фестиваль быел өченче мәртәбә уздырылды. Анда 13 илдән 600дән артык кеше катнашкан. Алар вокал, нәфис сүз, бию номинацияләрендә көч сынашкан. Әлфия Авзалованың кызы, аның исемендәге фонд җитәкчесе Зөлфия Авзалова-Нигъмәтҗанова сүзләренә караганда, быел чит илләрдән катнашучылар азрак булган.

– Румыния, Болгариядән җыр һәм бию ансамбльләренең чыгышларын онлайн режимда карадык. Алар лауреат булды. Бу – бик үзенчәлекле концерт. Ул Әлфия Авзалова рухына багышлана. Фестивальдә үзебез өчен кызыклы артистлар, яшь талантлар ачтык. Быел җюри составы да зур иде, бик көчле бәйге булды. Үзебезнең конкурслар белән гастроль турлары да оештырырбыз дип ышанам. Фестивальне үткәреп, әниемнең васыятен үтим, – диде Зөлфия ханым.

«Татар-информ»

Әлфия Авзалова исемендәге III Халыкара фестиваль-бәйгесендә Гран-прига яшь җырчы Татьяна Ефремова лаек булды.

Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы

ОЧРАШУ УРЫНЫ – КАЗАН

«Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйгесе дәвам итә. Республиканың төрле районнары, башкалага килеп, якташларын җыеп, зур гына бәйрәм уздыра. «ВТ» хәбәрчеләре дә шундый бәйрәмнәрнең берничәсендә булып кайтты.

Теләче

Килгән кунакларны фольклор коллективлары, үзешчән башкаручылар, Теләче районының тарихи мирасын, мәдәниятен чагылдырган күргәзмәләр каршы алды. Милли ризыклардан сыгылып торган табыннардагы тәм-томнар белән һәркем сыйлана алды.

Күргәзмәләр рәте буенча йөрибез. Күзем шәхси эшмәкәр Лилия Колупаевның рәт-рәт тезелеп куелган кәрзиннәренә төште. Бу кәсеп белән 3–4 ел шөгыльләнә икән ул. Җәһәт кенә аның белән әңгәмә корып алдык.

– 8–9 яшемдә әнием мине макраме эшләргә өйрәтте. Кызыксынуым шуннан башланды. Флорист булып эшләгәндә матур кәрзиннәр кирәк иде. Бер останы табып, сатып алдым. Аннары үзем дә бу һөнәрне үзләштердем, – дип сөйләде ул.

Биш литрлы кәрзинне бер сәгать ярым-ике сәгать эчендә үрә икән Лилия.

– Вакыты кәрзиннең зурлыгына һәм нинди әйбер белән үрелүенә карый. Кәрзиннәрне сатуга да, үзем өчен дә эшлим. Бөтен йортым һәм бакчам шулар белән тулган. Әле мин мастер-классларда да үткәрәм. Шулай берсендә инсульт кичергән хатын-кыз килде. Барысын да бик тырышып, җентекләп эшләде. Хәзер дә дәвам итә. Берничәдәр вакыттан соң аның куллары җиңелрәк хәрәкәтләнә башлады, хәтта сөйләме яхшырды. Кул эше чирне җиңәргә дә ярдәм итә ул, – диде Лилия Колупаева.

Теләче районы үзешчән сәнгать осталары тамашачыларны концерт белән дә сөендерде. Концерт алдыннан Олы Мишә авылының «Ядкәр» фольклор ансамбле белән аралаштык. «Ядкәр» – авылның мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре, китапханәчеләреннән торган коллектив. Араларында 40, 30ар ел гомерләрен шушы өлкәгә багышлаучылар бар.

– Төркемебездә – алты кеше. Сәхнәдә дә чыгыш ясыйбыз, төрле чараларда да актив катнашабыз. Хәзер менә мобилизацияләнгән егетләребезгә җылы оекбашлар бәйлибез. Авылдашлар да булышырга килә. Ветераннарыбызны котлыйбыз, табигатькә чыгабыз, килен каршыларга яшьләр туйларына да чакыралар, аулак өйләр үткәрәбез. Бер тик тормыйбыз, – дип сөйләде коллективка йөрүче Рузалия Газизова.

Концерт залында якташларын Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗипов сәламләде.

– Бүген биредә Теләче районының тырыш халкы, җыр-моңга гашыйк сәнгать осталары җыелды. Казанда чыгыш ясау – районыбыз өчен дәрәҗә, мәртәбә белән бергә, зур җаваплылык та өсти. Чараны оештыручыларга ихлас рәхмәтемне белдерәм. Бүген Теләче ныклы адымнар белән алга атлый. Район данын еракларга таратучы якташларыбыз киләчәк буын өчен затлы мирас калдыра, – диде Нәҗип Хаҗипов.

Аның сүзләрен Татарстан мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов куәтләде:

– Теләче – бай мирасы, зур тарихы, татар рухлы район. Ул гел үсештә, хезмәттә. Теләче – көрәшчеләр районы да. Сәхнәдә яшь талантлар да күрәштәге кебек беренче минуттан ук игътибарны җәлеп итте.

Ләйсән САФИНА

Теләчеләләр концертында үзешчән сәнгать йолдызлары белән бергә танылган артистлар да чыгыш ясады.

Аксубай

Аксубайлыларны каларга дип автобуста барганда бер төркем апаларның сөйләшүе колагыма чалынды. «Эштән иртәрәк киттем – көн дә килмиләр бит. Авылга да еш кайтып булмый», – ди берсе. «Алдан ярминкәсе була аның. Быел бал алмаган идем, Аксубай балын алып килми калмаганнардыр», – ди икенчесе.

Бал турында әйткән ханым хаклы булып чыкты. «Әкият» курчак театрына кергәндә бер яклап азык-төлек (шул исәптән, бал да), агач эшләнмәләр, мунча өчен кирәк-ярак һәм башкасын тәкъдим иттеләр. Икенче якта исә чуашларның данлыклы куасын татып карарга була иде. Иске Тимошкино авылыннан Галина Андреева чуаш куасы әзерләүнең кайбер серләрен дә сөйләде. «Бер тәүлек вакытының һәм мәхәббәтеңне кызганмасаң, телеңне йотарлык килеп чыга!» – диде ул.

Сүз уңаеннан, Аксубайда халык саны буенча нәкъ менә чуашлар – беренче урында. Районда барлыгы 27955 кеше яши, шуларның 12301е – чуашлар, 10791е – татарлар, 4753е – руслар, 101е – калган милләтләр.

Шуңа да ярминкәне карап бетереп, театр бинасына узганчы, шушы өч төп халыкның бию көйләренә басу мәслихәт иде булса кирәк. Һәрхәлдә, ул тирәдән тыныч кына узып китү кыен иде.

Урамнан кергәч, Аксубайның яшәеше белән таныштыру мөмкинлеге булды. Район тарихына, Аксубайның горурлыгы булган шәхесләргә, яшь буынның уңышларына багышланган күргәзмәләр, кул эше осталарының хезмәтләре, әллә ничә төрле остаханә – кичке сәгать алтыда башланасы концертка юкка гына дүрттән үк агыла башламаганнар икән халык. Бер якта – изү-калфаклар ясау, икенче якта тамбурлы чигү серләренә өйрәттеләр, чуашларның символлары ясалган карточкалар ярдәмендә киләчәкне дә фаразлап карадылар. Мин исә иң чуар һәм затлы өстәл янында торучы Әлфия ханым Нурхаматова белән аралашырга ашыктым. XIX гасырда Казан татарлары арасында популяр булган һәм онытыла язган тырнак алмалау техникасы белән чигелгән эшләнмәләрен тәкъдим итте ул. «Вак-вак тукыма кисәкчекләреннән җыела ул. Әүвәлге заманнарда бу исул белән бай хатын-кызлар калфакларын бизәткән. Вакытлар узуга, тырнак алмалау техникасы онытыла язган. Шөкер, инде ничә ел аны торгызу максатыннан армый-талмый хезмәт куям», – дип сөйләде оста.

Концерт башланганчы, район башлыгы Камил Гыйльмановны да күреп сөйләштек. Аксубайны тәкъдим итәргә 20лап автобуста 400ләп кеше килде, дип шаккатырды ул.

– Районыбызны төрле яклап күрсәтергә телибез. Аксубай – «кара алтын»га, кара туфракка бай төбәк, дияргә яратабыз. Әмма безнең төп байлык – кешеләребез. Аксубайда күпмилләтле, бердәм, тырыш халык яши. Курыкмыйча әйтә алам: бездә милли проблема юк. Барлык бәйрәмнәр өч телдә уза, барлык милләтләр дә бер-берсенә хөрмәт белән карый, – дип сөйләде ул.

Сәхнәдә дә районда яшәүче өч төп халыкның бәйрәмнәрен (Сабан туе, Троица, Уяв) тәкъдим итте аксубайлылар. Натурализмны да кызганмадылар: Сабан туенда егетләр чыгып бил алыштылар, җиңгән көрәшчегә район башлыгы машина ачкычы тапшырды, тамашачылар Троица боткасы белән сыйланды...

Тагын шуңа игътибар иттем: концертта катнашучылар арасында дүрт яшьлек баянчыдан алып, 80не узган әбиләргә кадәр бар иде. Ул сәләтле малай әле кашыкчы да булып чыкты. Дәрәү кубып алкышларга кумелгән чыгышның берсе шул булса, чәчләренә чал кунган әби-бабайларның вальс әйләнүе – икенчесе.

Әгерҗе

Татарстан Халыклар Дуслыгы йортына килгән кунакларны фольклор коллективлары дәртле җырлар белән каршы алды. Мәдәният көнен бөтен Әгерҗе җыелган кебек иде. Зал шыгрым тулды, урыннар җитми башлады хәтта. Шунлыктан концертны басып караучылар да хәйран булды. Тик Әгерҗе халкына бу комачауламады, якташлары белән җылы очрашуга сөенеп утырды алар. Кунаклар арасында өлкән буынның да, яшьләрнең дә булуы аеруча сөендерде. Аларны татар, рус, мари, удмурт халыкларының милли ризыклары белән сыйладылар. Районның үзешчән сәнгать осталары «Төньяк йолдызым син – Әгерҗем» дигән тамаша тәкъдим итте.

– Әгерҗедә гомер-гомергә дус һәм тату, бер-берсен хөрмәт итеп һәм аңлашып, төрле милләт вәкилләре яши. Һәр халык үзенең тарихы һәм традицияләре белән бөек. Бу бәйрәм сезгә туган якка булган хисләрне яңартырга ярдәм итсен, – дип сәламләде якташларын Әгерҗе районы башлыгы Ленар Нургаянов.

Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов районның төп байлыгы хезмәт сөючән һәм талантлы кешеләре булуын әйтте.

– Әгерҗе районы матур табигате, тарихы һәм хезмәт казанышлары белән дан тота. Әгерҗе – зур һәм мөһим тимер юл төене. Бу төен әлеге күпмилләтле җирнең халыкларын ныклы дуслык белән бәйләгән. Сез намус белән эшли һәм рәхәтләнеп ял итә беләсез. Үз халкыгызның гореф-гадәтләрен саклап, сез Татарстанның мәдәни күптөрлелеген үстерүгә зур өлеш кертәсез, – дип сөйләде Айрат Зарипов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Белдерү

Информация для потребителей электрической энергии СНТ «Любитель природы-2»

Государственный комитет Республики Татарстан по тарифам на основании пункта 16 Основных положений функционирования розничных рынков электрической энергии, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 04.05.2012 г. № 442 (далее – Основные положения), информирует потребителей электрической энергии СНТ «Любитель природы-2» о следующем:

1. В соответствии с абзацем 8 пункта 15 Основных положений АО «Татэнергосбыт» уведомил Государственный комитет Республики Татарстан по тарифам об отказе от исполнения договора энергоснабжения от 01.02.2014 г. №8543 Э, заключенного между АО «Татэнергосбыт» и СНТ «Любитель природы-2», в связи с ненадлежащим исполнением СНТ «Любитель природы-2» обязательств по оплате.

2. АО «Татэнергосбыт» – гарантирующий поставщик, обязанный принять на обслуживание потребителей СНТ «Любитель природы-2», энергопринимающие устройства которых расположены в границах зоны его деятельности.

Платежные реквизиты АО «Татэнергосбыт»:
ИНН 1657082308 КПП 165901001
Р/с 40702810845030000258 в ПАО «АК БАРС» Банк г. Казани
К/с 30101810000000000805
БИК 049205805

3. Дата и время для принятия АО «Татэнергосбыт» на обслуживание потребителей СНТ «Любитель природы-2»: 01.11.2023 г. с 00 часов 00 минут.

4. Потребителям СНТ «Любитель природы-2» необходимо снять показания приборов учета на 01.11.2023 г. 00 часов 00 минут и передать их не позднее 2 месяцев с даты снятия в адрес гарантирующего поставщика, предложение о заключении договора которого принято потребителем в соответствии с пунктом 21 Основных положений, либо в иных случаях – в адрес сетевой организации, с которой потребителем заключен договор оказания услуг по передаче электрической энергии, а при незаключении такого договора – в адрес сетевой организации, к объектам электросетевого хозяйства которой присоединены энергопринимающие устройства потребителя. При этом если лицом, ответственным за снятие показаний приборов учета, является сетевая организация, такие показания передаются в адрес соответствующего гарантирующего поставщика не позднее 10 рабочих дней с даты их снятия.

5. Не позднее 2 месяцев с 01.11.2023 г. потребителями должны быть заключены договоры, обеспечивающие продажу электрической энергии (мощности), с условием о продаже им электрической энергии (мощности) начиная с 01.11.2023 г.

6. На основании пункта 26 Основных положений, в случае, если такие договоры не будут заключены, сетевая организация к электрическим сетям которой непосредственно или опосредованно присоединены энергопринимающие устройства потребителей, обслуживаемых СНТ «Любитель природы-2»:

выявляет лиц, которые не заключили договоры, обеспечивающие продажу им электрической энергии (мощности), и при этом фактически потребляют электрическую энергию;

составляет в установленном настоящим документом порядке акт о неучтенном потреблении электрической энергии;

рассчитывает в соответствии с настоящим документом объемы бездоговорного потребления электрической энергии за период, истекший с даты, установленной для принятия гарантирующим поставщиком на обслуживание потребителей;

принимает меры по сокращению уровня или прекращению потребления электрической энергии в отсутствие договора и по обеспечению оплаты объемов электрической энергии, потребляемой без заключенного договора лицом, потребляющим электрическую энергию, путем введения ограничения режима потребления электрической энергии.

Кадастровым инженером ООО «АЗИМУТ-ГЕО» Бересневой Татьяной Николаевной (номер квалификационного аттестата: 16-13-625; выдан 09.09.2013 г., почтовый адрес: 420088, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тургай, д. 21, e-mail: beresntatyana@yandex.ru, контактный телефон: 89046658592) выполняются кадастровые работы по уточнению границы и площади земельного участка с кадастровым номером 16:50:250704:562, с категорией земель – земли населённых пунктов, с разрешенным использованием – садоводство, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, с/т «Медик», участок 46.

Заказчиком кадастровых работ является Музафаров Руслан Владимирович (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 43а, кв. 175, контактный телефон: +79867125119).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится 25 ноября 2023 г. в 10.00 ч. по адресу: РТ, г. Зеленодольск, ул. Ленина, д. 30.

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ, содержащихся в межевом плане, и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются в течение 30 календарных дней по адресу: РТ, г. Зеленодольск, ул. Ленина, д. 30, контактный телефон: +78437155383, +79395055383.

Смежный земельный участок, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ в связи с уточнением границ земельного участка: 16:50:250704:570, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, сдт «Медик», участок 57.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

КОТЛЫЙБЫЗ!

Бүген **Харис Бәдретдин улы КАМАЛИЕВның** туган көне. Республика авыл хуҗалыгын үстерүгә ифрат зур өлеш керткән, тәҗрибәсе белән бик теләп уртаклашучы, ихтирамлы, мәрхәмәтле, фикерен төгәл җиткерү сәләтенә ия, юмор хисенә бай шәхес ул.

Тәтеш районының бай тарихлы Үтәмеш авылында туып-үскән егет, Казанда авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаганнан соң, республиканың байтак кына хуҗалыкларында, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында баш агроном вазыйфасында була.

2005 елда һөнәре буенча кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары – «Татмелиорация» берләшмәсе генераль директоры, «Татсортсемовощ» берләшмәсе генераль директоры буларак та хезмәт коллективының, республика җитәкчелегенең хөрмәтен казана. Хәзер ул – яхшы сыйфатлы орлыклар җитештереп, шуларны халыкка җиткерүче «Семена» сәүдә йорты директоры.

«Тәтеш» якташлык җәмгыяте җитәкчесе буларак та тарихны барлауда, якташларын данлауда тырышлыгын кызганмый.

Әле шушы көннәрдә генә Татарстан Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов республика агросәнәгате ветераны Харис Бәдретдин улына «Дуслык» ордены тапшырды. Чын күңелдән тәбрик итәбез, киләчәктә дә нык сәламәтлек, халкыбызга озын-озак хезмәт итүен телибез.

Туганнары, дуслары, фикердәшләре

МАМАДЫШ «ПУТИН»Ы

ВЛАДИМИР КРАСЮКОВНЫҢ ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯ ЗОНАСЫНДА АЛГАН КУШАМАТЫ БУ

Ватан хакына

Владимир Красюков, узган елның март аенда үз теләге белән килешү төзеп, махсус хәрби операциягә китә. Яралланганнан соң, аны ике айга ялга кайтаралар. Владимирның госпитальгә китәренә бер көн кала, безгә дә аның белән сөйләшергә насыйп булды.

– Түбәндә туган егет мин. Язмыш кушуы белән Чаллыга кайтып урнашкан идем. Шәһәр шау-шуы күңелемә ошамады. Тыныч урын эзләдем. Мамадыш районының Түбән Ушма авылыннан йорт сатып алдым. Йортны бер күрүдә ошаттым. Авылны да, кешеләрен дә яраттым, – дип сөйли Владимир. – Ялга кайтканнан бирле бар кеше минем тирәмдә бөтерелә. Хикмәт нидә соң, дим. Ватан саклаучы егетләр мин генә түгел инде. Телевизордан да күрсәттеләр, район журналистлары да килде. Аптырадым әле мин. Менә тагын сез дә минем хакта язмакчы буласыз.

Владимир Владимировичның махсус хәрби операциядәге кушаматындадыр хикмәт. Безгә дә авылдашлары үз «Путин»ыбыз бар дигәч, аптырап та киткән идек. Баксаң, йөзгә дә охшаш булып чыкты алар. Бу исемне аңа «Тимер» батальонында кушалар. Егетнең башта үзенә «Фәрештә» исемен аласы килгән була. Бу хакта әйткәч, командирдан: «Сугыш кырында синсез дә фәрештәләр күп, «Путин» булырсың», – дигән җавап ала.

Эльмира Ми ңнекәева

Владимир анда укчы булып хезмәт иткән. Хәрби бәрелешләр вакытында кулы каты яраланган. Табиблар, егетнең кулын саклар өчен, барысын да эшли. Кулына Илизаров аппаратын беркетәләр. Октябрь ахырында Ростов госпиталендә егеткә тагын бер операция ясалачак. Шуннан соң Владимирның яңадан үз ротасына барып кушылу теләге бар.

– Үлем белән күп тапкырлар күзгә-күз очрашкан бар. Әмма анда курку хисе югала. Бер уй – дошманны юк итү! Бертуктаусыз яңгыраган шартлау тавышына да ияләшәсең икән. Ир-ат икәнсең, куркып торып булмый. Ватанны сакларга, якларга кирәк. Без дә бирешсәк, сезне кем яклар?! – ди ул.

Владимир 9 июльне икенче туган көне дип әйтә ала. Нәкъ шул көнне танк шартлый. Егет каты яралана.

– Беттем инде дигән идем. Якыннарымны башка күрә алмам дип уйладым. Бәхеткә, янәшәмдәге солдат ярдәмгә килде. Ул минем кулымны бәйләде, үземне куркынычсыз урынга чыгарды һәм табибларга тапшырды. Ә үзе кире китте. Озак та үтмәде, мине үлемнән йолып калган дустым бер аяксыз, бер кулсыз калды, икенче кулындагы өч бармагын югалтты. Бик кызганыч, – ди Владимир.

Владимир Красюковка «Батырлык өчен» медале биргәннәр. Әмма ул үзен геройга санамый. «Мин – гап-гади бер кеше», – ди.

– Үземә булган хөрмәттән күңелем тула. Авылдашларым якын итәләр. Алты ел элек килеп урнашкан Түбән Ушма бик якын җиргә әйләнде. Монда кешеләр ачык күңелле. Кайтуга, кызым янына мәктәпкә бардым. Укытучылар кочак җәеп каршы алды. Балалар алдында чыгыш ясавымны да сорадылар. Әле менә китәргә җыенганда, яныма мәктәп директоры килде. Шулкадәр гади ханым. Синең хакта стенд ясыйбыз, дип тора. Мондый игътибардан соң әллә ничек булып китте. Оялдым да, – ди ул. – Газета аша Түбән Ушма халкына рәхмәтемне җиткерәсем килә. Миңа, гаиләмә терәк булганнары өчен башымны иям. Татар авылында күңелгә тынычлык табып яшим. Йортыбыз да мәчет янәшәсендә. Исән-имин әйләнеп кайтып, шушы авылда гомер итәсе иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА



Өзелмәсен өмет

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кар-буранлы кыш та көттермәс. Суык чорның – үз мәшәкате. Марс Тукаев әйтүенчә, ярдәм кулы сузарга теләүчеләр Бөтендөнья татар конгрессына мөрәҗәгать итә ала. Битараф булмаучылар киемнәр белән дә, акчалата да, башкача да булышырга мөмкин.

– Кыш айларына да күп калмады. Конгресс шундый карар кабул итте: авыл халкына 3 һәм 6шар мең сум акча бүлеп биреләчәк. Бу акча кышкы кием-салым алуга тотылачак. Авылдагы бөтен кешегә дә әләгәчәк матди ярдәм бу, – диде Марс Тукаев.

Янгыннан урманнар, кырлар да зыян күрде. Авыл кешесе өчен гаилә әгъзасыдай кадерле булган малларын да аямады ул. Исән калган малын бетермәсен иде халык.

– Җәй дә коры килде. Печән әзерләү мөмкинлеге булмады диярлек. Авыл халкы мал-туарын бетермәсен өчен, һәр мал башына 1 рулон печән бирергә җыенабыз. Шушы көннәрдә анысын да Йолдыз халкына тапшырачаклар, – дип сөйләде Марс Тукаев. – Әле шушы көннәрдә генә Курганга тагын бер йөк машинасы тутырып ярдәм җибәрдек. Сүз уңаеннан, Бөтенроссия татар авыллары иҗтимагый оешмасы рәисе Фәнир Галимов 10 караватт әзерләп куйган иде. Йөк машинасы Курганга барышлый, Туймазыга кереп, аның шәхси ярдәмен дә алып китте.

Кадерле нигез

Шушы авылда гомер итүче Изольда Сабированың да хәлен белештек.

– Авылда калган халык Татарстанга рәхмәт укый. Шәхсән үзем дә рәхмәт әйтергә телим. Ярдәмегездән ташламадыгыз, булыша алганча булышасыз, хәл белешеп торасыз. Авылда өйләр салына. Вакытында тапшырып торалар. Шулай да әле өй көтүчеләр күп. Бездә инде кар ява, тиздән кыш җитәчәк. Шуңа да борчыла халык. Алга таба ни булыр инде… Өй туйлары шаулап-гөрләп үтә, димәс идем. Чөнки синең өең була торып, башканың баш очында түбәсе булмаганда, зурлап нидер уздыру яхшы түгел. Ул ягын да уйлыйсың.

Ирина Колдина да, йортка тизрәк күченәсе иде инде, ди.

– Йортны төзиләр, кайчан төзеп бетерерләр, белмим. Сертификатның кечкенәсе эләкте миңа. Күп нәрсәне үз көчебез белән булдырабыз, сатып алабыз. Киявем алтын куллы, ул күп нәрсәне үзе эшләячәк, – диде ул. Әңгәмәдәшнең маллары да бар: атлар һәм бозаулар тоталар. Әлегә вакытлыча дип бирелгән бер йортта яшиләр.

Май аеның утлы фаҗигасеннән зыян күрүчеләр арасында Гариповлар гаиләсе дә була. Аларга да тиздән яңа өй ачкычын тапшырачаклар. Тимер-бетон панельдән яңа йорт сафка бастырганнар. Яңасы зуррак та әле – 53 квадрат метр икән.

– Курган өлкәсеннән 2 млн 400 мең сумлык сертификат, ипотека-торак корпорациясе тагын 700 мең сум биргән иде. Элекке йортыбыз 47 квадрат метр иде, – ди гаилә башлыгы Фәрит Гарипов. – Авылдан китү турында уйлап та карамадык. Шәһәр тормышы ошамый безгә. Йолдызда яшәячәкбез.

…Яңа нигезгә аяк басу теләге белән яшәгәннәргә дә бәхет тизрәк елмайсын иде инде. Йолдызда яшәячәкбез һәм авылны яшәтәчәкбез, дип торалар бит әнә!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ӘТИ-ӘНИ ДОГАСЫНА ПӘРДӘ ЮК

Язылганга кире кайтып

«Теләгебез кабул булды». Моннан бер ел элек: «Үзебез исән-сау чагында улыбызны бик тә гаиләле итәсе килә», – дигән Светлана һәм Илдус Хәмидуллиннар бүген шулай дип шөкер итә. Сау-сәламәт туып, тәпи китеп, инде тәүге сүзләрен әйтә башлаган, грипп белән авырганнан соң башта ишетү, аннан сөйләшү сәләтен югалткан уллары Илдарның язмышы өчен борчылып шулай дигән иде алар.

Илдус – Балтач районының Иске Салавыч авылы егете. Тормыш иптәше Светлана белән ерак Казахстан җирендә танышалар, гаилә коралар. Бәхетләрен тулыландырып, уллары Илдар туа. Сау-сәламәт булып туа, тәпи китә, «әннә-әттә», «мәм-мәм» дигән сүзләре белән теле дә ачылып килә. Тик бер яшь тә ике ай дигәндә уллары ангина белән авырып, хастаханәгә эләгәләр. Анда исә грипп белән авыручы балалар күп була. Шулай итеп, ангинага грипп та өстәлә һәм грипп дигәнең эзсез калмый: бераздан инде Илдарның эндәшүгә, тавышка игътибар итмәве ачыклана. Шулай да өметләрен өзмиләр, вакытлыча гына булыр, ишетә башлар дип көтәләр. Көтәләр дигәч тә, көтеп кенә утырмый алар. Ике колагы тиң ишетү сәләтен югалткан сабыйларын кайларга гына алып бармый, нинди генә дәвалау курслары үтми Хәмидуллиннар. Кытай медицинасы да калмый, Мәскәве дә… Барысы да өметләндерсә дә, алга китеш күренми. Ишетмәгән бала моңа кадәр әйтә торган сүзләрен дә оныта…

Илдарга ике яшь тулганда гаилә Илдусның туган ягына кайтып төпләнә. 25 ел хуҗалыкта алдынгы шоферларның берсе булды ул. Светасы да, мөмкинлек булуга, фермага, бозаулар карарга керә. Үз хуҗалыкларында бүгенгәчә күп итеп мал-туар, кош-корт асрап яшиләр. Илдарга иптәшкә Рузалия һәм Лилия исемле сеңелкәшләр дә алып кайталар. Илдарны якындагы махсус мәктәпләр үзләренә кабул итми: Алабугадагы интернат-мәктәпкә урнаштырырга туры килә. Бу мәктәп турында өлкәннәр бик мактап искә ала. «Сигез ел укыттык, андагы өч ел ике сыйныфка санала, укуын тагын да дәвам иттерәсе килгән иде, тик ара бик ерак, хәзерге кебек машиналар заманы да түгел. Шул сәбәпле Алабугадан Казанга күчергән идек. Анда олырак малайлар каһәрләгән булып чыкты. Безне, улыгыз югалды, килегез, дип чакырттылар. Өч тәүлек шундагы подвалда утырган булып чыкты. «Монда калмыйм», – дип елагач, алып кайттык инде. Шөкер, укый-яза белә, телефоннан үз тиңнәре белән аралаша ала. Ул инде хәзер безнең сөйләмне иреннәрдән дә укый. Таныш булмаган кешеләр белән аралашканда гына аңлап бетерә алмый», – дип сөйләгән иде Света.

Алабугада Илдар укырга-язарга гына түгел, рәсем ясарга да, кул эшләренә дә өйрәнә. Монда кайткач, мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында булган күптөрле район конкурсларында катнаша, җиңә, призлы урыннар ала. Кул эшләнмәләре белән дә яратып шөгыльләнә. Хәзер инде күп вакытын маллар янында, бакчада-ихатада эшләп үткәрә. Бер минут тик тора белми, ди якыннары.

Менә шушындый тырыш, уңган егетнең язмышы турындагы язмабыз бик күпләрне битараф калдырмады. Әтиәни догасына пәрдә юк, диләр. Аларның чын йөрәктән теләгәннәре быел чынга аша. Илдар интернетта райондашы, Субаш авылы кызы Алинә белән таныша, аралаша башлыйлар. Алинә дә – тормыш сынаулары аша үткән, чыныккан кыз. Илдар кебек үк, ул да сау-сәламәт туа, салкын тиеп авырганнан соң, начар ишетә башлый, сөйләме дә авырлаша. Казандагы махсус мәктәптә укый, бүген аппарат ярдәмендә ишетә, шөкер, авырданрак булса да, сөйләшә ала. Интернет аша аралашкан яшьләр быелгы җәйге бәйрәмнәрнең берсендә очрашып, сөйләшә. Аннан инде, икесенең дә туган көннәрен сылтау итеп, гаиләләре очрашып таныша. Октябрьнең матур бер көнендә Хәмидуллиннар килен төшерә.

– Алинәбез нәкъ абый кебек, бик тырыш, уңган. Чигә, бәйли, бик матур итеп бии, үзенә өстәмә һөнәр дә алган. Бәхетле генә булсыннар, без алар өчен бик шат, – ди Илдарның сеңлесе Рузалия.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 345

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+